Гавами тыңлаулар башлану турында
ХӘБӘРНАМӘ

Әлеге хәбәрнамә белән «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кичкеево авылы янында «Август-Кайбыч» ҖЧҖнең тәүлеклек җайга салу бассейны булган сугару челтәрен төзү» линияле объекты территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. 1 том. Территорияне планлаштыру проектының төп өлеше;
2. 2 том. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар уздыру срогы 2025 елның 07 октябре.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны:

-Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Надеждино ав., Клуб ур., 1й.;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково ав., Мәктәп ур. 39й.;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Багай ав., Үзәк ур., 28й.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2025 елның 07 октябренә кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Татарстан Республикасы Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә 2025 елның 07 октябренә кадәр язма рәвештә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2025 елның 07 октябрендә 17.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 й.   адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Сайтка килүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru) һәм:

- Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы,  Надеждино ав., Клуб ур.,  1й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы,  Ульянково ав., Мәктәп ур.  39й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Багай ав., Үзәк ур., 28й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Башкарма комитеты мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Җитәкче А.Н. Макаров